ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 5 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 7; 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү турында яисә аларның исемнәрен алмаштыру хакында тәкъдимнәрне карау турындагы Татарстан Республикасы законында» сүзләрен «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 23 июлендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законы)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяның 6 өлешендә «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

3) 20 статьяда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турындагы тәкъдимнәрне карау хакындагы Татарстан Республикасы законында» сүзләрен «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 21 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктында «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга исем бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турындагы тәкъдимнәрне карау хакында Татарстан Республикасы законында» сүзләрен «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законында» сүзләренә алмаштырырга;

5) 22 статьяның 1 өлешендәге 8 пунктында «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү турында яисә аларның исемнәрен алмаштыру хакында тәкъдимнәрне карау турында Татарстан Республикасы законында» сүзләрен «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законында» сүзләренә алмаштырырга;

6) 24 статьяда:

а) 1 өлештә:

5 пунктта «кертелмәү» сүзен «кертелү» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктта «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турында тәкъдимнәрне карау хакында Татарстан Республикасы законында» сүзләрен «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә:

6 пунктта «кертелмәү» сүзен «кертелү» сүзенә алмаштырырга;

11 пунктта «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турында тәкъдимнәрне карау хакында Татарстан Республикасы законында» сүзләрен «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законында» сүзләренә алмаштырырга;

7) 25 статьяда:

а) 1 өлештә:

5 пунктта «кертелмәү» сүзен «кертелү» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктта «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турында тәкъдимнәрне карау хакында Татарстан Республикасы законында» сүзләрен «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең 6 пунктында «кертелмәү» сүзен «кертелү» сүзенә алмаштырырга;

в) 3 өлешнең 5 пунктында «кертелмәү» сүзен «кертелү» сүзенә алмаштырырга;

г) 4 өлешнең 6 пунктында «кертелмәү» сүзен «кертелү» сүзенә алмаштырырга;

8) 26 статьяның 7 пунктында «кертелмәү» сүзен «кертелү» сүзенә алмаштырырга;

9) 28 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрында административ-территориаль берәмлекләрнең һәм торак пунктларның рәсми исемнәре рус һәм татар телләрендә бирелә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестры аны алып баруга вәкаләтле орган тарафыннан үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм актуаль хәлдә тотыла.»;

10) 29 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 27 июнь
№ 53-ТРЗ